КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 13 ноябрь г.Казань № 1038

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 316 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 316 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 26 гыйнвар, 20 нче; 2007 ел, 28 апрель, 149 нчы; 2008 ел, 28 гыйнвар, 38 нче; 2008 ел, 25 июль, 534 нче; 2009 ел, 5 март, 125 нче; 2009 ел, 8 май, 283 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1033 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 1 июль, 533 нче; 2012 ел, 10 март, 205 нче; 2012 ел, 9 июнь, 503 нче; 2013 ел, 18 март, 175 нче; 2013 ел, 30 ноябрь, 946 нчы; 2014 ел, 18 апрель, 254 нче; 2014 ел, 1 ноябрь, 842 нче; 2015 ел, 2 октябрь, 736 нчы; 2016 ел, 23 март, 157 нче; 2016 ел, 28 июль, 523 нче; 2016 ел, 17 август, 568 нче; 2016 ел, 7 декабрь, 904 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 971 нче; 2017 ел, 27 март, 188 нче; 2017 ел, 29 август, 611 нче; 2017 ел, 22 сентябрь, 711 нче; 2018 ел, 25 май, 398 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1215 нче; 2019 ел, 24 июнь, 509 нчы; 2019 ел, 25 июль, 619 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 нче пунктның унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«нәселле терлекчелек өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге (03.02.06*).»;

3.2 нче пунктның унтугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты белән балык тоту, су объектларын һәм су биоресурсларын файдалану һәм саклау өлкәсендә идарә итү функцияләрен гамәлгә ашырганда (01.06.05*);»;

3.3 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«нәсел продукциясенә (материалга) тиешле экспертиза ясауны тәэмин итә;

нәселле терлекләрнең дәүләт китабын алып бара;

Татарстан Республикасында нәселле терлекчелекне үстерү буенча дәүләт программасын эшләүне һәм тормышка ашыруны оештыра;

бонитирлаштыру турындагы мәгълүматларны гомумиләштерә һәм, югары бәяләнә торган нәселле хайваннарны нәтиҗәле файдалануны стимуллаштыру максатларында, аның нәтиҗәләре турында кызыксынган затларга хәбәр итә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин